**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯХШЫЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам, 18 нче йорт.
Тел.(885552)3-44-45.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423765, с. Верхнее Яхшеево, ул. Новая,
дом 18. Тел.(885552) 3-44-45.
E-mail Diliya.Mirzaeva@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**от «18» декабрь 2021ел** **№ 22**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 18 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеше), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Югары Яхшый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советының, 2014 елның 20 ноябрендәге 18 номерлы «Җир салымы турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренең милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы объектлардан тыш, мәгариф, фән, физик культура һәм спорт, сәнгать объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;».

1.2. 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге12 нче абзац белән тулыландырырга:

«-сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,6%».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Югары Яхшый авылы, Үзәк урамы, 27а йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Түбән Яхшый авылы, Г. Тукай урамы, 48 нче йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Табанлы Күл авылы, Гагарин урамы, 55 нче йорт адреслары буенча, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы, Югары Яхшый авыл җирлеге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы « Югары Яхшый авыл җирлегенең рәсми сайтында», «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет-телекоммуникация челтәрендәге бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Югары Яхшый авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе

Зиннатуллина Җ. Г.